

Корбаннын сvзенен мəгънəсе «Якынаю, Аллаһка якынайта торган нəрсə» дип бирелə. Дини терминологиядə исə, ул «билгеле талəплəргə туры килгəн хайванны, гыйбадəт нияте белəн, ысулына туры китереп чалу» дип билгелəнə.
Ел саен, борынгы гореф-гадəтлəрне саклап, Кыр корбанын Зубово-Поляны районы Кочетовка авылы халкы, жирле халык Цатока ди, зурлап vткəрə. Бу йола борынгыдан килгəн һəм бvгенге конгə кадəр сирəк урыннарда сакланып калган гореф-гадəт буенча башкырыла. Бик тə уникаль һəм матур кvренешлəрнен берсе. Əйтеп китəргə кирəк, ел саен Зубово-Поляны районындагы оч кечкенə авыл халкы – Кочетовка – Цатока, яки Чатока да дилəр, Татар Лунданы, Горенка Кыр корбаны бəйрəмен əби-бабалары ихтирам иткəн һəм, гадəт буенча, һəр авылда ул я май аенда, я булмаса, жəй башында vтеп килə.      Бəйрəм дога кылу белəн башлана. Аннары Аллахы Тəгалəдəн уныш мул булып vсvне, доньяларда тынычлык һəм авыллары иминлектə булуны, табигатьнен рəхимле – кочле жил-давылсыз, кочле янгырсыз булуын сорыйлар. Бəйрəм алдыннан авыл халкы оч кон кырда намаз укыйлар. Оченче конне, намаздан сон, корбан бугазлыйлар. Барлык ислам дине елаларын Цатока авылы мəчете имамы Вахит Хайдяр улы Немешев башкара.
Кыр корбанына Цатока авылынын яше-карты жыела дисəк тə ялгышмабыз дип уйлыйм. Авылдашлар шушы олы милли бəйрəмне бергə-бергə əзерли, хəтта Мəскəвдə, Питерда яшəvче якташлары сəдака жибəреп бəйрəмдə читтəн торып катнаша. Шул акчаларга корбан итəр очен сарык алалар, аннары казаннарда ит, салма пешереп бар кунакларны сыйлыйлар. Быел да нəкъ шулай була. Халык чəчəкле - vлəнле кырда рəхəтлəнеп аш-су əзерлилəр дə, сыйланалар да. Авылдагы бер кешене дə онытмыйча, гадəт буенча, сыйлыйлар, хəтта килə алмаганнарны да. Кырга, Кыр корбаны бəйрəменə килə алмаган картларыбызга, аш-суны ойлəренə илтеп бирəбез, дилəр.
Аерым рəхмəтне Цатока авылы халкы Амалия Маминага истəлеккə ясаган фотолары очен əйтəлəр.

**Наилə НАСЫРОВА**